ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 06.09.2023
1328 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының социаль-икътисади үсеше рейтингы буенча ведомствоара комиссия төзү турында

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 4 октябрендәге 356 номерлы боерыгы нигезендә, Алабуга муниципаль районы рейтингын бәяләүнең объективлыгын арттыру, шулай ук, югары вазифаи затларның эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү кысаларында Татарстан Республикасы алдында торган бурычларны исәпкә алып, Алабуга муниципаль районы үсеше күрсәткечләре исемлеген актуальләштерү максатында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының социаль-икътисади үсеше рейтингы буенча ведомствоара комиссия төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының социаль-икътисади үсеше рейтингы буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасары Р.А. Мусаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
06.09.2023 1328номерлы
карарына 1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының социаль-икътисади үсеше рейтингы буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Мусаев Р.А. | Икътисади үсеш буенча АМР Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Курамшин Н.Д. | АМР Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Демина Ю.В. | «Алабуга шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры |
| Костюкова О.Ю. | ТР буенча Дәүләт статистикасының Алабуга бүлеге башлыгы |
| Садыйкова Э.И. | АМР Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Шәрипов Р.А. | «АМР Башкарма комитеты каршында төзелеш департаменты» МКУ директоры |
| Сәфәров Р.Р. | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы |
| Буланова Р.П. | АМР Башкарма комитетының ГХТИ бүлеге башлыгы |
| Карлина С.В. | . Икътисад тармакларын анализлау, фаразлау һәм үстерү бүлеге башлыгы |
| Зарипова Е.В. | Инвестицион үсеш бүлеге башлыгы |
| Закирова Р.Л. | Федераль салым хезмәтенең ТР буенча 9 нчы районара инспекциясе башлыгы |
| Косов А.В. | АМР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы |
| Е.А. Йосыпова | Икътисад тармакларын анализлау, фаразлау һәм үстерү бүлегенең баш белгече |

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының социаль-икътисади үсеше рейтингы буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының социаль-икътисади үсеше рейтингы буенча ведомствоара комиссиясе(алга таба Комиссия) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 4 октябрендәге 356 номерлы боерыгы нигезендә төзелде.

2. Комиссия Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан расланган Алабуга муниципаль районында социаль-икътисади үсеше күрсәткечләренә ирешү максатларында, Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары, оешмалары һәм предприятиеләре гамәлләрен консолидацияләүне тәэмин итүче даими эшләүче консультатив-киңәшмә органы булып тора.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, Алабуга шәһәре һәм Алабуга муниципаль районы җирле үзидарәсенең норматив хокукый актлары, башка норматив хокукый документларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

4. Үз эшчәнлеге барышында Комиссия:

- Алабуга муниципаль районының социаль-икътисади үсеше күрсәткечләренә ирешүгә бәйле аеруча актуаль мәсьәләләр һәм проблемалар турында фикер алышуны оештыра;

- Алабуга муниципаль районының үсеш күрсәткечләре исемлеген актуальләштерүгә ярдәм итә;

- Алабуга муниципаль районының социаль-икътисадыиүсеше рейтингы күрсәткечләренең артуына ярдәм итә.

5. Комиссия юридик зат булмый һәм үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

6. Комиссия составына: Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланган комиссия җитәкчесе, секретаре һәм комиссия әгъзалары керә.

7. Комиссия җитәкчесе һәм секретаре комиссиянең беренче оештыру утырышында комиссия әгъзалары арасыннан сайлана.

8. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кимендә кварталга бер тапкыр уздырыла. Комиссия утырышын үткәрү турында карарны җитәкче кабул итә.

9. Комиссия әгъзаларын яңа әгъзалар составына кертү һәм аның составыннан төшереп калдыру мәсьәләләре эш утырышында карала.

10. Комиссия утырышлар үткәрүне үз эченә алган эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итүне комиссия секретаре гамәлгә ашыра.

11. Комиссия утырышында комиссия җитәкчесе рәислек итә.

12. Комиссия карарлары коллегиаль, гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, ведомствоара комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

13. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул җитәкче тарафыннан раслана.

14. Комиссия карарлары киңәш характерында була һәм Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә мәгълүмат алу һәм эштә файдалану өчен җибәрелә.

15. Комиссияләр үз компетенциясенә кагылышлы барлык мәсьәләләр буенча карар кабул итәргә хокуклы: комиссия турында Нигезләмәне һәм аның шәхси составын үзгәртү буенча тәкъдимнәр әзерләргә; эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләргә.

16. Комиссия турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән кертелә.

17. Комиссия эшчәнлеген туктату Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла.